

Мордовия Госсобраниесе депутаты, Мордовия Республикасы Сәvдә-сәнәгать палатасы директоры Ринат Раимов vткән атна эшләренә кvз салыйк.
Депутатлар һәм федераль хокvмәт әгъзаларынын уртак фикер алышу темасы автоматлаштыру һәм хезмәт житештерvчәнлеген кvтәрv буенча Россия Госдумасы жыелышында Мордовиядән Госсобрание житәкчесе Владимир Чибиркин, анын урынбасарлары Сергей Вдовин һәм Евгений Тюрин, Икътисад, Сәнәгать һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Ринат Раимов, фракция житәкчесе Тимур Гераськин, республиканын берничә министрлыгы вәкилләре катнаштылар.      - Хезмәт житештерvчәнлеген арттыру һәм житештерvне автоматлаштыру мәсьәләләре бик мөһим. Моннан башка икътисад vсешенен югары темпларына ирешеп булмый, конкуренцияне жинеп булмый, - дип билгеләп vтте vз чыгышында Россия Дәvләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин.
Фикер алышу барышында билгеләп vтелгәнчә, хезмәт житештерvчәнлеген арттыру – илнен суверенитеты, Россияне аерым цивилизация буларак саклау мәсьәләсе. Ин мөһим бурычлар арасында vз робот техникасын vстерv һәм квалификацияле кадрлар әзерләv аталды. Пленар утырышта Россия Хокvмәте әгъзалары һәм Дәvләт Думасы комитетлары житәкчеләре чыгыш ясады. Депутатлар хезмәт житештерvчәнлеген алга таба vстерергә ярдәм итә торган чаралар тәкъдим иттеләр.



Тагы бер очрашу уздырылды. Бу кызык иде: Дубенка белән Поводимово мәктәпләренен олкән сый-ныф укучылары һәм аларнын сыйныф житәкчеләре Мор-довия Госсобрание депутаты Ринат Раимов ярдәме белән тобәк парламентында булдылар. Экскурсия очен темалар республиканын дәvләт символлары, хаки-миятнен закон чыгару органы тарихы, анын структурасы, бурычлары һәм функцияләре булды. Мордовия Госсобрание житәкчесе урынбасары Наталья Долматова vз vрнәгендә укучыларга закон чыгаручыларнын эше турында сойләде. Патриотлыкнын мөһимлеге, халыкнын рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм традицияләрен саклау, гаилә монәсәбәтләрен ныгыту, шулай ук яшьләрнен буыннар элемтәсенә ярдәм итvдә, илнен һәм республиканын киләчәген формалаштыруда зур роле турында сvз барды. Ринат Раимов та депутат буларак эшләнгән эшләре турында укучыларга сойләде.
Госсобрание депутаты Ринат Рафик улы Раимов гражданнарны да кабул итте. Депутатка Саранск кешесе, сугыш хәрәкәтләре ветераны Вячеслав Кокурин морәжәгать белән килгән. Махсус хәрби операциядән кайткач, ул эшмәкәрлек белән шогыльләнә башлый, ләкин билгеле бер кыенлыклар белән очраша. Морәжәгать итvчене тынлагач, депутат вәзгыятьне ачыкларга һәм ярдәм кvрсәтергә вәгъдә итте. Мәсьәлә парламент контроленә алынды.

*Наилэ НАСЫРОВА эзерлэде,*
*Фотолар Госсобрание РМ сайтыннан*